ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Г.Тукая, д.60, с.Шишинер, 422268

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Г.Тукай ур.,60 нчы йорт,Шеңшеңәр ав.,422268

Тел.: (84368) 3-98-24, факс: (84368) 3-98-57. E-mail: Shn.Blt@tatar.ru www.baltasi.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
29.05.2023

КАРАР
№ 9

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә ”Гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 09 декабрендәге 17 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 09.12.2016 № 17 (17.11.2020 № 14 үзгәрешләр белән) карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында”нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Беренчел хәрби исәпкә алу Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәре тарафыннан башкарыла (алга таба – хәрби исәп хезмәткәре).»;

1.2. 1.2 пунктта «Беренчел хәрби исәпкә алу» сүзләрен «Хәрби исәп хезмәткәре» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Балтач муниципаль районы буенча бүлеге белән берлектә алар территориясендә яшәүче һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле яшәүче яисә 3 айдан артык вакыт булучы граңданнарны,шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлү булмаган затларны,.»;

1.4. 3.7 пунктына «Россия Федерациясе Саклану министрлыгы билгеләгән форма буенча» сүзләрен өстәргә;

1.5. 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Ел саен Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына 1 октябрьгә кадәр 15 яшькә җиткән ир-ат җенесендәге гражданнар һәм 16 яшькә җиткән ир-ат җенесендәге гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр - киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле ир-ат җенесендәге гражданнар исемлекләрен тапшырырга.»;

1.6. 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек буенча аларның бурычларын аңлатырга, аларның үтәлешен тикшереп торырга, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында мәгълүмат бирергә.”;

1.7. түбәндәге эчтәлекле 3.10 һәм 3.11 пунктлар өстәргә:

«3.10. Беренчел хәрби исәпкә алу документларын Россия Федерациясе Саклану министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм рәвештә машина язуы һәм электрон төрләрдә сакларга

3.11. Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәгән очраклары турында белешмәләр тапшырырга.»;

1.8 4.1пунктта:

икенче абзацта «авыл җирлегенең» сүзләрен «җирле үзидарә органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «администрациясенең» сүзен «башкарма комитетының» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «авыл җирлекләре» сүзләрен «җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 5.1пунктта «хәрби исәпкә алу буенча» сүзләрен «беренчел хәрби исәпкә алу буенча» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 09.12.2016 елгы 17 нче номерлы карары белән расланган Шеңшеңәр авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Беренчел хәрби исәпкә алу документларында булган белешмәләрне җыюны, саклауны һәм эшкәртүне тәэмин итү максатларында хәрби исәп хезмәткәре бурычлы:

1) тикшерергә:

а) хәрби билетларның булуын һәм дөреслеген (хәрби билетлар урынына бирелгән белешмәләр, хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыклар)яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларын,шулай ук аларда язмаларның дөреслеген, мобилизацион күрсәтмәләр булуын (хәрби билетларда аларны тапшыру турында билгеләр булган очракта хәрби бурычлылар өчен), гражданнарның элеккеге яшәү урыныннан исәптән төшерү турында хәрби исәпкә алу документларында тамга булуын,Россия Федерациясе гражданнары паспортларында аларның хәрби бурычларга мөнәсәбәте турында тамгаларның булуын, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең шәхси номерлары булган жетоннарны (хәрби билетларда аларны тапшыру турында тамгалар булган очракта хәрби запастагылар өчен) һәм шәхси электрон карталарны;

б) хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына белешмә, хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыклар) һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларының гражданның паспорт мәгълүматларына туры килүе, фотографияләр булу һәм аның хуҗасына тиңдәшлеге, ә хәрби

билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыкларда,моннан тыш, яраклылык вакыты да.

в) гражданнарның элеккеге яшәү урыны буенча хәрби исәптән төшерү турында тамга һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның һәм запастагы офицерларның яңа яшәү урыны буенча хәрби комиссариатта хәрби исәпкә кую турында тамга булу;

г) хәрби билетларда (хәрби билетлар урынына бирелгән белешмәләр, вакытлы таныклыклар), хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларында, мобилизацион күрсәтмәләрдә хәрби исәпкә куелу турында тамга булмаган очракларда хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарны һәм запастагы офицерларны яшәү урыны буенча хәрби комиссариатка җибәрәләр.

д) хәрби билетларда (хәрби билетлар урынына бирелгән белешмәләр,хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлы таныклыклар) хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларында, мобилизацион күрсәтмәләрдә килешенмәгән төзәтмәләр, төгәлсезлекләр,тулы булмаган битләр табылганда,бу хакта,тиешле чаралар күрү өчен, Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына хәбәр итәләр;

2) гражданнардан хәрби билет (хәрби билет урынына бирелгән белешмә, вакытлы таныклык)яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданның таныклыгын алганда документ хуҗасына расписка бирергә;

3) хәрби билетлардагы язмалар (хәрби билетлар урынына бирелгән белешмәләр, вакытлы таныклыклар) нигезендә, запас офицерларына беренчел исәп карточкаларын тутырганда, прапорщикларга, мичманнарга, старшиналарга, сержантларга, запастагы солдатларга һәм матросларга алфавит карточкаларын тутырганда, армиягә чакырылучыларның учет карталарын тутырганда һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларында гаилә хәле, белеме, эш урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яисә гражданнарның вакытлыча булу урыны турында белешмәләрне һәм хәрби исәпкә алына торган гражданнар документларындагы кирәкле башка белешмәләрне төгәлләштерергә;

4) запас офицерларының беренчел исәпкә алу карточкаларын, алфавит карточкаларын, солдатларның (матросларның), сержантларның (старшиналарның), запас прапорщикларның (мичманнарның) исәп карталарын һәм хезмәткә чакырылучыларның учет карталарын исәпкә алу картотекасының тиешле бүлекләренә урнаштырырга;

5) хәрби билетлар (хәрби билетлар урынына белешмәләр, вакытлыча таныклыклар), прапорщикларның, мичманнарның, старшиналарның, сержантларның, солдатларның һәм запастагы матросларның алфавит һәм учет карточкалары, мобилизацион күрсәтмәләр, алфавит һәм учет карточкаларын тутырмыйча хәрби исәпкә алынган гражданнар исемлеге, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыклары һәм исемлеге, шулай ук хәрби бурычларга гражданнар мөнәсәбәте турында аларда булмаган тамгалар белән Россия Федерациясе гражданнарының паспорты, хәрби хезмәткә алуны рәсмиләштерү өчен, муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатларына ике атналык срокта тапшырыла;

6) мобилизацион күрсәтмәләр белән бергә хәрби исәптән төшерелгән гражданнар исемлеген мәгълүмат алмашу буенча дәфтәргә ике атна эчендә төзергә һәм Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына тапшырырга;

Район чикләрендә яшәү урынын үзгәрткән гражданнарга мәгълүмат алмашу буенча Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына дәфтәр тутырырга һәм җибәрергә (бу гражданнарга учет карточкалары һәм алфавит карточкалары тутырылмый).

7) хәрби исәптән төшерелгән гражданнарның беренчел хәрби исәп документларын Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатының исәпкә алынган мәгълүматлар белән чираттагы чагыштыруга кадәр сакларга, шуннан соң аларны акт төзү белән билгеләнгән тәртип нигезендә юкка чыгарырга;

8) ел саен, 1 февральгә кадәр, Балтач муниципаль районы хәрби комиссариатына узган елда беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисаплар тапшырырга;

9) Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан оешмаларны исәпкә алу һәм аларда хәрби исәпкә алуны тикшереп тору максатларында:

-«Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак урыннарны, мәгариф һәм башка оешмаларны эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеген» журналын (исемлеген) алып барырга;

- ел саен беренчел хәрби исәпкә алу документларын оешмаларның хәрби исәпкә алу документлары белән тикшертергә;

-беренчел хәрби исәпкә алу документларын оешмаларның хәрби исәпкә алу документларын тикшерү планын һәм оешмаларны тикшерү планын төзергә.

Тикшергәннән соң, запаста торучы гражданнарның хәрби исәбен алып бару журналында тикшерү язмасы ясарга.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихҗанов